**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**20.12.2018** **№ 2779**

2019 елга «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетик юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 14 декабрендәге 854 нче номерлы «Татарстан Республикасы балаларга сәнгать-эстетик юнәлешендәге өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» карары һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.2019 елга түбәндәгеләрне кушымта нигезендә расларга:

«Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең сәнгати-эстетик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар (кушымта);

балаларга сәнгати-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата 0,5 күләмендә төзәтмәләр коэффициентын.

2. «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә тарала.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - мәгариф бүлеге башлыгы Н.К. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

Кушымта

РАСЛАНДЫ
«Биектау муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге
башкарма комитетының 2018
елның 20 декабрендәге 2779
номерлы карары белән

«Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга сәнгати-эстетик юнәлешендәге өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә
НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАРЫ

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокациясе | Норматив чыгымнар (1 укучыга елга сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык укыту срогы | дүрт еллык укыту срогы | биш еллык укыту срогы | җиде еллык укыту срогы | иртә һөнәри юнәлеш |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | | | 60 519 | 70 105 | 90 982 |
| Рәсем сәнгате | авыл җирлеге | | 33 235 | | 28 980 | 69 559 |
| Хореографик сәнгать | авыл җирлеге | | | 63 795 | 52 609 | 191 884 |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 27 818 | | |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 60 079 | 57 660 | 93 239 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 92 265 | | 88 340 | | 145 742 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 47 585 | | 44 206 | 44 213 | 69 610 |